

Жылы кояш нурларына торенеп, йогерек горлəвеклəре белəн йогереп язнын беренче ае - март та килеп житте. Барыбызга да билгеле, əлеге айнын ин матур, ин олы бəйрəме - 8 Март - Халыкара хатын-кызлар коне.

Мордовия хатын-кызларын ихластан “Юлдаш” ин кvркəм тантаналарнын берсе - Халыкара хатын-кызлар коне белəн ихластан тəбрик итə!        Хатын-кыз - ул тулы бер донья, анын кvнеленə мəхəббəт тə, гvзəллек тə, йомшаклык та, ин кочле Ана хислəре дə, гаилə учагы жылысы да сыйган. Бvген хатын-кызларнын кvпчелеге эш белəн мəшгуль. Ул балалар да vстерə, йорт-жирне дə карый - аны якты һəм жылы итə, остəвенə, карьера ясый һəм шушы мен торле мəшəкатьлəргə чумып калмыйча, vзенен нəзакəтлелеген дə саклый белə. Боларны бары тик хатын-кыз гына булдыра ала.

Кадерле хатын-кызлар - əнилəр,əбилəр, апалар, сенеллəр! Шушы гажəеп гvзəл бəйрəм конендə елмаеп баккан кояштай һəрвакыт балкып яшəгез. Кvнелегездəн шатлык, тəнегездəн саулык-сəламəтлек, йортыгыздан иминлек - бəракəт китмəсен! Бəйрəм белəн!